| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 февраль 2024 ел № 1142

Башкарма комитетның «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10494 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә, Яр Чаллы шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәсенең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен шартлар тудыру максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2023 елның 31 октябрендәге 10494 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны шәһәр бюджеты акчалары хисабына 40 962,08 мең сум: 2024 ел – 29 962,08 мең сум, 2025 ел – 5 500,0 мең сум, 2026 ел – 5 500,0 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 22 февралендәге
1142 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2023 елның 31 октябрендәге
10494 номерлы карарына
кушымта

1 бүлек. «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаның исеме | «2024-2026 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы карары белән расланган шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2014 елның 17 апрелендәге 30/18 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре,<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре,<br>Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаның максаты | Территориаль иҗтимагый үзидарәнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен Яр Чаллы шәһәре халкын территориаль иҗтимагый үзидарәне (алга таба – ТИҮ) үстерү процессына җәлеп итү.<br>2. Халыкның социаль әһәмияткә ия инициативаларын тормышка ашыру өчен җирле үзидарә органының ТИҮ оешмалары белән үзара эшчәнлеген оештыруны камилләштерү.<br>3. ТИҮ оешмалары эшчәнлегенең сыйфатын арттыру өчен шартлар булдыру. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2024 - 2026 еллар:<br>- 1 этап – 2024 ел;<br>- 2 этап – 2025 ел;<br>- 3 этап – 2026 ел. |

<table>
<tr><td rowspan="8">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары (мең сум)</td></tr>
<tr><td>2024 ел</td><td>2025 ел</td><td>2026 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>5 500,0</td><td>5 500,0</td><td>5 500,0</td><td>16 500,0</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>24 462,08</td><td>-</td><td>-</td><td>24 462,08</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>29 962,08</td><td>5 500,0</td><td>5 500,0</td><td>40 962,08</td></tr>
<tr><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруга тотыла торган акчаларның күләме шәһәр бюджеты мөмкинлекләреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге инфляция процессларыннан һәм икътисадый хәлдән чыгып анықланырга һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2026 елга түбәндәгеләргә ирешү күздә тотыла:<br>1) ТИҮ эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп ителгән шәһәрдә яшәүчеләр саны арту;<br>2) халыкны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү;<br>3) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм ТИҮ оешмалары арасында үзара эшчәнлекне яхшырту;<br>4) ТИҮне материаль-техник тәмин итү исәбенә эш сыйфатын арттыру, эшләрне башкару срокларын кыскарту;<br>5) Яр Чаллы шәһәренең ТИҮ системасын үстерү.</td></tr>
<tr><td>Программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="5">Программаның үтәлешенә гомуми контрольне Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

2 бүлек. Программаны тормышка ашыру өлкәсе характеристикалары, күрсәтелгән өлкәдәге төп проблемаларга тасвирлама һәм аны үстерү прогнозы

ТИҮ мөстәкыйль рәвештә һәм үз җаваплылыгында җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыру өчен, яшәү урыны буенча шәһәр территориясе өлешләрендә гражданнарның үзоешмасы булып тора.

ТИҮ эшчәнлегенең төп максаты булып гражданнарның тормыш сыйфатын арттыру, үсеш алган гражданнар җәмгыяте төзү, җирле әһәмияткә ия бик кирәкле проблемаларны һәм аерым мәсьәләләрне үз инициативасы белән чишү тора. ТИҮ бер үк вакытта халык хакимияте структуралары сыйфатында да, коммерцияле булмаган хуҗалык итү субъектлары сыйфатында да эш итә, җирле үзидарә бурычларын хәл итүдә катнашуга гражданнарны җәлеп итүдә төп рольне үти.

ТИҮ җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча халыкның үз инициативаларын тормышка ашыруга мөмкинлек бирә һәм җирле берләшмәләрнең проблемаларын хәл итүдә мөһим роль уйный.

Беренчедән, ТИҮ – җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен Яр Чаллы шәһәре халкының интеллектуаль, фәнни, мәдәни потенциалын киң файдалану мәйданчыгы ул.

Икенчедән, ТИҮ халык проблемалары һәм сораулары турындагы мәгълүмат оператив рәвештә җирле үзидарә органнарына барып ирешә торган, оештырылган мәгълүмат каналы булып тора. Шул ук вакытта, ТИҮ органнары җирле үзидарә органнарыннан мөһим мәгълүматны халыкка җиткерү чарасы да булырга мөмкин.

Өченчедән, ТИҮ – ачыкланган проблемаларны чишү, гражданнарның үз запросларын үзләре хәл итү өчен төп чара.

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә 78 ТИҮ рәсми теркәлгән һәм эшли.

Яр Чаллы шәһәрендә ТИҮ системасын формалаштыру тәгалләнә һәм шуның өчен ул җирле үзидарә органнары ягыннан җайга салуга, камилләштерүгә һәм ярдәмгә мохтаҗ.

Гамәлдәге ТИҮнең эш процессында күп кенә төп проблемалар ачыкланды:

1) территорияләрне үстерү проблемаларын хәл иткәндә гражданнар җәмгыятенең активлык дәрәҗәсе түбән булу;

2) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, ТИҮ оешмалары арасында үзара эшчәнлек механизмнары камил булмау;

3) ТИҮнең материаль-техник ятан тәэмин ителеше җитәрлек булмау;

4) ТИҮ оештыру һәм аның эшчәнлек юнәлешләре мәсьәләләре буенча халыкның хәбәрдарлык дәрәҗәсе түбән булу;

5) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен ТИҮ потенциалыннан җитәрлек файдаланмау.

Барлык программа чараларын уңышлы тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:

1) ТИҮ эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп ителгән Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр санын арттырырга;

2) халыкны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итәргә;

3) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм ТИҮ оешмалары арасында үзара эшчәнлекне яхшыртырга;

4) ТИҮне материаль-техник тэмин итү исәбенә эш сыйфатын арттырырга, эшләрне башкару срокларын кыскартырга.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары, аны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Максат – ТИҮнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1) җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен Яр Чаллы шәһәре халкын ТИҮне үстерү процессына җәлеп итү;

2) халыкның социаль әһәмияткә ия инициативаларын тормышка ашыру өчен җирле үзидарә органының ТИҮ оешмалары белән үзара эшчәнлеген оештыруны камилләштерү;

3) ТИҮ оешмалары эшчәнлегенең сыйфатын арттыру өчен шартлар булдыру.

Программа 2024-2026 елларда тормышка ашырыла.

Программаны тормышка ашыру этаплары:

- 1 этап – 2024 ел;
- 2 этап – 2025 ел;
- 3 этап – 2026 ел.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирүче индикаторлар

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрдән файдаланырга тәкъдим ителә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | ТИҮ эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп ителгән гражданнар саны, % | Дз = Чз / Чн х 100, монда:<br>Дз – ТИҮ эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп ителгән шәһәр халкының чагыштырма саны<br>Чз – ТИҮ оештырган чараларда катнашучы шәһәр халкының саны;<br>Чн – статистика мәгълүматлары буенча шәһәр халкы саны | Районнар хакимиятләре хисабы, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе мәгълүматы |
| 2. | ТИҮ тарафыннан игътибарга алынган социаль якланмаган гражданнар өлеше, % | Ди = Чзи / Чни х 100, монда:<br>Ди – ТИҮ тарафыннан игътибарга алынган социаль якланмаган гражданнар өлеше;<br>Чзи – ТИҮ тарафыннан игътибарга алынган социаль якланмаган гражданнар саны;<br>Чни – социаль якланмаган гражданнар саны; | Районнар хакимиятләре хисабы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәрендәге социаль яклау идарәсе мәгълүматы |
| 3. | Оргтехника һәм мебель белән җиһазландырылган ТИҮ өлеше, % | До = No / Nн х 100, монда<br>До – оргтехника һәм мебель белән җиһазландырылган ТИҮ өлеше;<br>No – оргтехника һәм мебель белән җиһазландырылган эш урыннары саны;<br>Nн – оргтехника һәм мебель белән җиһазландырылырга тиеш эш урыннары саны | Районнар хакимиятләре хисабы |
| 4. | ТИҮ тарафыннан оештырылган мәдәни-массакүләм чаралар саны, берәмлек | N – ТИҮ тарафыннан оештырылган мәдәни-массакүләм чаралар саны | Районнар хакимиятләре хисабы |
| 5. | ТИҮдә катнашучылар саны, кеше | N – ТИҮдә катнашучылар саны | Районнар хакимиятләре хисабы |
| 6. | Материаль стимуллаштыру рәвешендә акча алган ТИҮ активы әгъзалары саны, кеше | N – материаль стимуллаштыру рәвешендә акча алган ТИҮ активы әгъзалары саны | Районнар хакимиятләре хисабы |
| 7. | Үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | N – үткәрелгән очрашуларның гомуми саны | Районнар хакимиятләре хисабы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | ТИҮ тарафыннан оештырылган чараларга җәлеп ителгән Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр саны, кеше | N – ТИҮ тарафыннан оештырылган чараларга җәлеп ителгән шәһәрдә яшәүчеләр саны | Районнар хакимиятләре хисабы |

5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

2024-2026 елларга программаны финанслау күләме 40 962,08 мең сум тәшкил итә: 2024 ел – 29 962,08 мең сум, 2025 ел – 5500,00 мең сум, 2026 ел – 5500,00 мең сум.

6 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программа чараларын тормышка ашыру барышына контрольне Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе гамәлгә ашыра.

Программаның нәтиҗәлелеген анализлау Башкарма комитетның 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла.

7 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Чараларның исеме | Башкаручылар | Чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Программа чараларын муниципаль бюджеттан финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2023 (база) | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел |
| Максатның исеме: Территориаль иҗтимагый үзидарәнең тотрыклы эшләве һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру | | | | | | | | | | | |
| 1 нче бурычның исеме: Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен Яр Чаллы шәһәре халкын ТИҮне үстерү процессына җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Территорияне төзекләндерүне контрольдә тоту буенча рейдлар | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 1 | 1,5 | 2 | 2,5 | Финансланмый | | |
| 2. | Мәктәпкә әзерләнергә ярдәм ит | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 1 | 1,5 | 2 | 2,5 | Финансланмый | | |
| 3. | Өлкән буын ункөнлеге | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 1 | 1,5 | 2 | 2,5 | Финансланмый | | |
| 4. | Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр ункөнлеге | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 1 | 1,5 | 2 | 2,5 | Финансланмый | | |
| 5. | Ачык һавада кино күрсәтү | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 3 | 3,5 | 4 | 5 | Финансланмый | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Ишегалды бәйрәме | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 3 | 3,5 | 4 | 5 | Финансланмый | | |
| 7. | Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм ветераннар белән очрашулар | Районнар хакимиятләре | | Чарада катнашкан гражданнар өлеше, % | 1 | 1,5 | 2 | 2,5 | Финансланмый | | |
| 8. | «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2024-2026 еллар | Конкурста катнашучы ТИҮ саны | 50 | 78 | 78 | 78 | 500,0 | 500,0 | 500,0 |
| 2 нче бурычның исеме: Халыкның социаль әһәмияткә ия инициативаларын тормышка ашыру өчен җирле үзидарә органының ТИҮ оешмалары белән үзара эшчәнлеген оештыруны камилләштерү | | | | | | | | | | | |
| 9. | ТИҮ ассоциацияләрен һәм ТИҮ координацияләү үзәген үстерү эше | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | | Үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | Финансланмый | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Иҗтимагый әһәмияткә ия бурычларны тормышка ашыруга гражданнарны җәлеп итүнең нәтиҗәле формасы буларак ТИҮ советларын үстерү эше | Районнар хакимиятләре | | Үткәрелгән очрашулар саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | **Финансланмый** | | |
| 11. | Халык белән эшләүдә ТИҮ эшчәнлеген активлаштыру, социаль яклау чараларына мохтаҗ гражданнарга аеруча игътибар күрсәтү | Районнар хакимиятләре | | ТИҮ тарафыннан ярдәм күрстәлә торган социаль якланмаган гражданнар өлеше, % | 4 | 5 | 6 | 7 | **Финансланмый** | | |
| 3 нче бурычның исеме: ТИҮ оешмалары эшчәнлегенең сыйфатын арттыру өчен шартлар булдыру. | | | | | | | | | | | |
| 12. | «Иң яхшы ТИҮ практикасы» конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм | 2024-2026 еллар | ТИҮ тарафыннан тормышка ашырылган практикалар саны, бер. | - | 25 | 30 | 35 | 5 000,0 | 5 000,0 | 5 000,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | күрсәтү өлешендә) | | | | | | | | | |
| 13. | Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләре җитәкчеләре тарафыннан компенсация түләүләре алу | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (оештыруда ярдәм күрсәтү өлешендә) | 2024-2026 еллар | Яр Чаллы шәһәре территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы ТИҮ саны/Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация түләүләре алучы ТИҮ саны | 78/78 | 78/78 | 78/78 | 78/78 | 24 462,08 | | |
| | Барлыгы: | | | | | | | | - | - | - |
| | Программа буенча барлыгы: | | | | | | | | 29 962,08 | 5500,0 | 5500,0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева